ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ СПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ

ӘҖМӘР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

КАРАР

№74-2 «14» сентября 2022 ел

Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Әҗмәр авыл җирлеге Советының 2017 елның 16 августындагы 37-2 номерлы карары белән расланган Әҗмәр авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә даими нигездә муниципаль вазыйфаларны биләүче затларга еллык түләүле ял бирү тәртибе һәм шартлары турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында

РФ Хезмәт Кодексы, муниципаль хезмәттурында Татарстан Республикасы кодексы, ТР Спас муниципаль районы Әҗмәравылҗирлеге Советы нигезендә

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы ӘҗмәравылҗирлегеСоветының 2017 елның 16 августындагы 37-2 номерлы карары белән расланган Әҗмәр авыл җирлегендә даими нигездә муниципаль вазыйфаларны биләүче затларга еллык түләүле ял бирү тәртибе һәм шартлары турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 6 пунктныкиләсередакциядәбәянитәргә:

«6. Тиешле еллар эшләгән өчен муниципаль хезмәткәргә ел саен өстәмә түләүле отпуск озынлыгы муниципаль хезмәтнең һәр елы өчен бер календарь көн исәбеннән исәпләнә. Еллык төп түләүле отпуск һәм ел саен өстәмә түләүле отпускның гомуми озынлыгы 40 календарь көннән артып китә алмый.Нормалаштырылмаган хезмәт көне билгеләнгән муниципаль хезмәткәргә нормалаштырылмаган хезмәт көне өчен өч календарь көндәвамында ел саен өстәмә түләүле отпуск бирелә».

1.2. Нигезләмәнең 7 пунктын "Хезмәт Кодексы башка чакар алмаган булса" сүзләренә өстәргә;

2. Әлеге карарны Спас муниципаль районының рәсми сайтында (http:/ www.spasskiy.tatarstan.ru) һәм хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (//http:pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

Әҗмәр авыл җирлеге башлыгы: Р.М.Вәлитов.

СОВЕТ ИЗМЕРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ